Республика Татарстан
Глава
Какре-Елгинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

ул. Советская, д. 22, село Какре-Елга, Азнакаевский район, 423320

Совет урамы, 22 нче йорт, Кәкре Елга авылы, Азнакай районы, 423320

Тел. (факс) 8(85592) 37-0-47; e-mail: Kelg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «30» октября 2023 г. № 1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясына ярашлы, муниципаль берәмлек башлыгы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 08 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якты Юл торак пункты, Кәкре Елга авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1

төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гаилә әгъзасы һәм гражданнар мобилизацияләнә, махсус операциягә юнәлтелгән, бер тапкыр түләүне киметү, аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Якты Юл торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын ремонтлауны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, килешү буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру) ;

- Яктыв Юл торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту( тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре);

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//Aznakayevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында..

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы И.М.Мөхәмәтҗанов